**ГЛАВА НОВОТУМБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ТУМБА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Тумба ав. **КАРАР**

02 октябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Яңа Тумба авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына кергән Покровский торак пунктын бетерү турында" карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү хакында

Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына кергән Покровский поселогын бетерү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Советы Карары проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Яңа Тумба авыл җирлеге Уставына таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына кергән Покровский поселогын бетерү турында» карары проекты буенча 2025 елның 26 сентябрендә җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан ителгән җәмәгать тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

ТР, Нурлат районы, Яңа Тумба ав., Шоссе ур., 1 й.;

ТР, Нурлат районы, Яңа Тумба ав., Шоссе ур., 4 й.

Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1 җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты - 2025 елның 22 октябрендә сәгать 10.00да;

2.2 үткәрү срогы - 1 көн;

2.3 үткәрү урыны - ТР, Нурлат районы, Яңа Тумба ав., Шоссе ур., 1 й.;

2.4 фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган, чыгыш ясау хокукы булган җәмәгать тыңлауларында катнашуга гаризалар бирелә торган адрес: ТР, Нурлат районы, Яңа Тумба авылы, Шоссе урамы, 1 йорт (эш көннәрендә-8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр)

2.5 чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2025 елның 15 октябренә кадәр.

3. Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына кергән Покровский поселогы торак пунктын

билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда бетерү турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Осипов